**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санын раслау турында» Указына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санын раслау турында» 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1215 номерлы Указының (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 29 гыйнварындагы ПУ-80 номерлы, 2014 елның 10 февралендәге ПУ-132 номерлы, 2014 елның 5 мартындагы ПУ-244 номерлы, 2014 елның 20 мартындагы ПУ-286 номерлы, 2014 елның 19 апрелендәге ПУ-405 номерлы, 2014 елның 26 апрелендәге ПУ-435 номерлы, 2014 елның 2 июлендәге ПУ-636 номерлы, 2014 елның 12 сентябрендәге ПУ-854 номерлы һәм 2014 елның 28 ноябрендәге ПУ-1091 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтасына, 18 пунктта «163» һәм «60» саннарын тиешенчә «216» һәм «113» саннарына алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

билгеләнгән тәртиптә әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә;

үзенең актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 16 март
№ ПУ-289

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ